# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2022 ел, 3 октябрь №132

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы, район башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 182 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы

карар итте:

1. “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 27 апрелендәге 142 номерлы карарына 1 нче кушымта” Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта “11498” санын “11958” санына алмаштырырга;

5 пунктта түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладның 5 % күләмендә айлык өстәмә түләү.

Муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган Татарстан Республикасы мактаулы исеме булу вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү өчен нигез булып тора.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Н.Гыйльфановка йөкләргә.

**Апас муниципаль районы**
**башлыгы-**
**Апас муниципаль районы Советы рәисе А.Г. Җиһаншин**